# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең Бәрлебаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

22 нче ноябрь 2023 ел №1

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирлеүзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 21 нче ноябрендә 10 сәгатьтә, 2023 елның 22 нче ноябрендә 09 сәгатьтә этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Бәрлебаш авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500(бишйөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- территорияне санкцияләнмәгән чүплекләрдән чистарту;
- авыл җирлеге торак пункты территориясен карап тоту;
- материаллар сатып алып, тротуар урнаштыру;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;
- су башняларын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү, моның өчен материаллар сатып алу;
-су башнясын лицензияләү буенча түләү (су белән тәэмин итү чыганагының артскважинасын куллану өчен санитар-эпидемиологик бәяләмәне документаль рәсмиләштерү, су анализы һәм башка документлар)

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту»

Экономия барлыкка килгән очракта,аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 121 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -65, бу 53,7 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Риза" позициясе өчен гражданнар җыенында 65 катнашучы тавыш бирде; "Каршы" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең Бәрлебаш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2.«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Бәрлебаш авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (бишйөз) сумм күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- территорияне санкцияләнмәгән чүплекләрдән чистарту;
- авыл җирлеге торак пункты территориясен карап тоту;
- материаллар сатып алып, тротуар урнаштыру;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- материаллар сатып алып, сууткәргеч челтәрләрен ремонтлау;
- су башняларын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү, моның өчен материаллар сатып алу;
-су башнясын лицензияләү буенча түләү (су белән тәэмин итү чыганагының артскважинасын куллану өчен санитар-эпидемиологик бәяләмәне документаль рәсмиләштерү, су анализы һәм башка документлар)

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Ябалак авыл җирлеге Башлыгы М.Ф.Гыйзәтуллина